# Дөньяда иң-иң матур тел –
# Ул минем Туган телем!

“Әйе” – яшел,

“Юк” – кызыл.

Яман гадәт тиз керә. (М).

# Тәмәке тарту, спиртлы эчемлекләр,наркотиклар кулланунын нәтиҗәсе









# Күңелсез күренешләр ...













# Карточка №1.

**Бирем. Калын хәрефләр белән бирелгән хәлләрне үзләре ияргән сүзләре белән язып алыгыз, сорау куегыз, белдерелү үзенчәлеген билгеләгез.**

***Үрнәк: Элеп (ничек?) күтәрәсез – I төр х.ф.***

1. Шатлык, сагыш күтәрәсез,
   Канатыгызга **элеп**. (Р.Әхмәтҗанов)
2. **Тырыша–тырыша** гармун уйный,
   Ул ничек онытылсын. (Халык җыры)
3. Яралганбыз бу дөньяда
   Яңа бер **болыт сыман**. (Зөлфәт)
4. Яшәргә язсын **елгадай,**
   Яшел ярларга тулып. (Зөлфәт)
5. Андый кеше янында син үзеңне **тыныч** һәм **ышанычлы** сизәсең. (М.Юныс)

Түбәндәге сораулар нигезендә рәвеш хәле турында модель төзергә.

1. Рәвеш хәле нәрсәне белдерә?
2. Сораулары нинди?
3. Ничек белдерелә?

# Өй эше

а) <u>“3”ле өчен</u> - Карточка №2.
Җөмләләрне күчереп языгыз, рәвеш хәлләренең асларына сызыгыз, белдерелү үзенчәлеген өсләрендә билгеләгез.

ә) <u>“4”ле өчен</u> - Рәвеш хәлләре кергән 5-6 мәкаль эзләп языгыз, рәвеш хәлләренең асларына сызыгыз.

б) <u>“5”ле өчен</u> - 105 нче күнегү. Бирелгән формаларны файдаланып, “Яхшы гадәтләр” темасына җөмләләр төзегез, җөмләдә ул сүз рәвеш хәле булып килсен.